**МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казань **БОЕРЫК**

03.09.2024 № 201

Татарстан Республикасы бюджетына
Татарстан Республикасы Гражданнар
оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр
Министрлыгы тарафыннан идарә ителә
торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә
өметсез дип тану турында карарлар
кабул итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел 6 нчы май № 393 «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләр турында» карары нигезендә боерык бирәм:

1. Бирелгән Татарстан Республикасы бюджетынаТатарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү Тәртибен расларга.
2. «Татарстан Республикасының янгын сагы» Татарстан Республикасы Дәүләт казна учреждениесенә, «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасы эзләү-коткару хезмәте» Татарстан Республикасы Дәүләт казна учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү Тәртибен эшләргә һәм расларга.
3. Әлеге боерыкны тарату хисабы нигезендә вазыйфаи затларга җиткерергә.
4. Бирелгән боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Н.В. Суржко

03.09.2024 № 201
Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү Тәртибе

1. Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы биредәге карарлар кабул итү Тәртибе (алда — Тәртип, Министрлык), Татарстан Республикасы бюджетына Министрлык тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану процедурасын билгеләү максатларында эшләнгән.

2. Министрлык тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче физик затның вафат булуы яисә аны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат дип игълан итү;

2.2. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча, күрсәтелгән Федераль закон нигезендә бурычны түләү вазыйфасыннан азат ителгән өлештә, гражданинның, шәхси эшмәкәрнең банкротлык процедурасын 2002 ел 26 нчы октябрь № 127-ФЗ «Милексезлек (банкротлык) турында» Федераль закон нигезендә тәмамлау;

2.3. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә оешманың мөлкәте җитмәү һәм (яисә) аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) түләп бетерә алмау сәбәпле түләнмәгән Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче оешманы бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә бетерү;

2.4. Амнистия яки ярлыкау турындагы актларны штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата куллану яки суд тарафыннан бюджет керемнәре администраторының Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы турында, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә карар кабул итү;

2.5. Әгәр, банкротлык турындагы эш буенча эш кузгату өчен аның милексезлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән күләме бурычлыга карата таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән биш елдан артык вакыт узган булса, башкару эшен

тәмамлау 2007 ел 2 нче октябрь № 229-ФЗ «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законның 46 нчы статьясындагы 1 нче өлешенең 3 яисә 4 нче пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтару вакытында суд приставы-башкаручының карар чыгаруы;

2.6. Банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедуралар үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану турындагы гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул итү яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату;

2.7. Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда оешманың мөлкәте җитмәү сәбәпле, түләп бетерелмәгән һәм аны күрсәтелгән оешманың гамәлгә куючыларының (катнашучыларының) түләп бетерергә мөмкин булмавы бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә 2007 ел 2 нче октябрь № 229-ФЗ «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законның 46 нчы статьясының 1 нче өлешенең 3 яисә 4 нче пунктларында каралган нигездә башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару эшен тәмамлау турында элек суд приставы-башкаручы тарафыннан чыгарылган карарның булуы Һәм теркәүче орган карары буенча юридик затны юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру. 2001 ел 8 нче август № 129-ФЗ «Юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон нигезендә теркәү органының юридик затны юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан чыгару турындагы карары гамәлгә яраксыз дип танылган очракта, бюджетка түләүләр буенча, элек биредәге пунктча нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бурыч, бюджет (бухгалтерлык) исәбенә кайтарылырга тиеш.

3. Тәртипнең 2 нче пунктында каралган очраклар белән беррәттән, әгәр административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар чыгарылса, түләнмәгән административ штрафлар түләтүгә өметсез дип таныла.

4. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

4.1. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләү буенча бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан әзерләнгән бурычның исәпкә алына торган суммалары турында Министрлык хисабыннан өземтәләр;

4.2. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүне тәэмин итү буенча бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан әзерләнгән күрелгән чаралар турында Министрлык белешмәләре;

4.3. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслаучы, шулай ук түбәндәге документлар:

физик затның – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүченең вафат булуын таныклый торган яисә аны үлгән дип игълан итү фактын раслый торган документ (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.1 нче пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс эшен тәмамлау яисә шәхси эшмәкәр булган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче граждан мөлкәтен сатуны тәмамлау турындагы суд акты, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче физик затның шәхси эшмәкәр буларак, аны милексез (банкрот) (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.2 нче пунктчасында күрсәтелгән очракта) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә эшчәнлеген туктатуы турында шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документы;

конкурс эшен тәмамлау яисә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче граждан мөлкәтен сатуны тәмамлау турында суд акты (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.2 нче пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче оешма бетерелүгә бәйле рәвештә эшчәнлеген туктату турында юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документ (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.3 нче пунктчасында күрсәтелгән очракта);

нигезендә бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта торган штраф яки суд акты рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки ярлыкау турындагы акт (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.4 нче пунктчасында күрсәтелгән очракта);

2007 ел 2 нче октябрь № 229-ФЗ «Башкару эшчәнлеге турында» Федераль законның 46 нчы статьясының 1 нче өлешенең 3 яисә 4 нче пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару эшен тәмамлау турында суд приставы–башкаручының карары (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.5, 2.6, 2.7 нче бүлекчәләрендә күрсәтелгән очракларда);

банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле бурычлыны милексез (банкрот) дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турындагы гаризаны кире кайтару турындагы суд акты (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.6 нчы пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Теркәүче орган карары буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче юридик затны күрсәтелгән реестрдан чыгару турында юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документы (Тәртипнең 2 нче пунктының 2.7 нче пунктчасында күрсәтелгән очракта);

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турындагы карар (Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән очракта).

5. Бурычны түләтүгә өметсез дип тану эшен оештыру максатларында, Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары һәм Комиссия әгъзалары составында, Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычны исәптән чыгару комиссиясе булдырыла (алда – Комиссия). Комиссиянең саны алты кеше тәшкил итә. Комиссиянең шәхси составы министр (аның вазыйфаларын башкаручы затның) (алда — министр) боерыгы белән раслана.

6. Комиссия рәисе:

Комиссия эшен җитәкли;

Комиссия утырышларын үткәрә;

Комиссия әгъзалары арасыннан Комиссиянең җаваплы сәркатибен билгеләп куя.

Рәис булмаганда аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссиянең җаваплы сәркатибе

Комиссия эшен алып баруны оештыра;

Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат белән тәэмин итә;

Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча Комиссия эше белән бәйле башка функцияләрне башкара.

8. Комиссия утырышлары кирәк булганча, әмма елына бер тапкырдан да ким түгел уздырыла. Әгәр Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, Комиссия карары тулы хокуклы дип санала.

9. Тәртипнең 4 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану нигезләрен раслый торган документлар пакеты Министрлыкка Тәртипнең 2 яисә 3 нче пунктында каралган очрак килеп чыгу турында мәгълүмат килгәннән соң утыз календарь көн эчендә Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан төзелә һәм Комиссиягә карауга җибәрелә.

10. Комиссия Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы соравын тапшырылган документлар нигезендә Комиссиягә килгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карый.

11. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы сорауны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

Тәртипнең 2 яисә 3 нче пунктында күрсәтелгән нигез, һәм Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документлар булганда, Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танырга;

Тәртипнең 2 яисә 3 нче пунктында күрсәтелгән нигез һәм Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документлар булмаганда Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип танымаска. Әлеге карар Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турындагы мәсьәләне кабат карауга комачауламый.

12. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән аның утырышта катнашучы әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

13. Тәртипнең 11 нче пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы йомгаклары буенча утырыш уздырылган көннән алып ун эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.

14. Комиссия утырышын уздырган көннән алып унбиш эш көне эчендә Комиссия карары түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта);

салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, оешманың салым түләүче исәбенә куелу сәбәбе коды (булган очракта физик затның салым түләүченең идентификация номеры);

бурыч барлыкка килгән Татарстан Республикасы бюджетына түләү турында белешмәләр;

Аның буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджетлары керемнәре классификациясе коды, аның исеме;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү датасы.

Акт утырышта рәислек итүче һәм утырышта булган комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

15. Комиссия тарафыннан рәсмиләштерелгән акт имзаланган көннән алып биш эш көне эчендә министр яисә аны алыштыручы зат тарафыннан раслана һәм билгеләнгән тәртиптә һәм норматив-хокукый документлар нигезендә түләтүгә өметсез бурычны бухгалтерлык исәбеннән төшереп калдыру өчен кирәкле гамәлләрне башкаручы бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә тапшырыла.

16. Тәртипнең 11 нче пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турында мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм Комиссия сәркатибе тарафыннан имзалана һәм министрга хәбәр итү өчен җибәрелә.

_______________